БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» 02 2021 ел № 76

Муниципаль контроль төрләренең һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының исемлеген раслау турында

«Тиешле эшчәнлек өлкәләрендә дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында һәм мондый контрольнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге турында докладлар әзерләү кагыйдәләрен раслау хакында» 2010 елның 5 апрелендәге 215 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын, «Тиешле эшчәнлек өлкәләрендә дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында һәм мондый контрольнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге турында докладлар әзерләү хакында» 2011елның 13 августындагы 676 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру максатларында, «Муниципаль контроль төрләренең һәм аларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының исемлеген һәм төрләрен алып бару тәртибен раслау турында» 2020 елның 16 декаберендәге 33 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгән Муниципаль контроль төрләренең һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының исемлеген расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://baltasi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

**Муниципаль контроль төрләренең һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының исемлеге**

| т/б № | Контроль төрләре | Муниципаль контрольне регламентлаштыручы норматив хокукый актлар | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган |
|---|---|---|---|
| 1. | Муниципаль торак контроле | 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, 131-ФЗ номерлы Законның 14 - 16 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты (төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге) |
| 2. | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контроль | «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1 өлеше, 131-ФЗ номерлы Законның 14-16 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты (төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Муниципаль җир контроле | 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексының 72 статьясы, 131-ФЗ номерлы Законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты һәм 16 статьясындагы 1 өлешенең 26 пункты | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы |
| 4. | Муниципаль урман контроле | 2006 елның 4 декаберендәге 200 – ФЗ номерлы Россия Федерациясе Урман кодексы | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы |
| 5. | Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон | Җирлек башлыклары |
| 6. | Җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контроль | «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы (2020 елның 8 декаберендәге редакциядә) Россия Федерациясе Законы | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы |